Кулланучы хәбәрләре

# Өйдә кем хуҗа?

## Фатир хуҗалары үз йортлары белән идарә итү алымын сайларга тиеш.

**Күп фатирлы йорт белән идарә итү буенча стандартлар һәм эшчәнлек кагыйдәләре, шулай ук хезмәт һәм эшләрнең минималь исемлеге составы, аларны күрсәтү һәм үтәү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә. Узган елның декабрендә торак законнарында кайбер үзгәрешләр булды.**



РФ Торак кодексы нигезендә, күп фатирлы йорт белән идарә итү анда яшәүче гражданнарга уңайлы һәм имин шартлар, гомуми милекне тиешенчә карап тоту һәм алардан файдалану мәсьәләләрен хәл итүне, шушы йортта яшәүче гражданнарга коммуналь хезмәтләр күрсәтүне, гомуми милек составына керә торган инженер коммуникацияләре һәм башка төрле җиһазларның даими әзерлеген тәэмин итәргә тиеш.

Күп фатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеге, торак милекчеләре ширкәте, торак кооперативы яки башка төрле махсуслашкан куллану кооперативы һәм РФ Торак кодексының 200 маддәсе 3 өлешендә каралган очракта мондый эшчәнлекне башкарудан тыш, аны алып бару өчен бирелгән лицензия нигезендә башкарыла.

2020 елның 22 декабрендә кабул ителгән «РФ Торак кодексының 161нче маддәсенә үзгәрешләр кертү турында»гы федераль закон (№ 441-ФЗ) нигезендә, РФ Торак кодексының 161 маддәсе 17 өлешенә үзгәрешләр кертелде. Хәзер, әгәр күп фатирлы йортта яшәүчеләр йорт белән идарә итү алымын сайламаса, ул чагында җирле үзидарә органы идарәче оешманы билгеләү турында карар кабул ителгәнчегә кадәр биш эш көне дәвамында күп фатирлы йорттагы барлык милекчеләргә югарыда аталган карарны кабул итү, бу йорт белән идарә итү килешүендәге шартлар һәм әлеге идарәче оешма белән идарә итү килешүен өзү шартлары хакында язма рәвештә хәбәр итә.

**Күп фатирлы йорт белән идарә итү килешүе җирле үзидарә органы тарафыннан идарәче оешманы билгеләү турында карар кабул ителгән көннән төзелгән дип санала.**

# Менюда – ит, ә тәлинкәдә... балык

**«Улым III сыйныфта укый. Бүген аңа нәрсә ашатачаклары минем өчен һәрвакытта да кызык. Әмма мәктәп сайтындагы меню һәрвакытта да чынлыктагы менюга туры килми. Мәктәптә тәкъдим ителгән менюдагы ашамлыкларны алыштырырга ярыймы?**

**Ирина П.»**



Чынлыктагы туклану рационы расланган менюга туры килергә тиеш. СанПиННың 6,22 пунктында 2.4.5.2409-08 («Гомуми белем бирү учреждениеләре, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучыларның туклануын оештыруга карата санитар-эпидемиологик таләпләр») шул хакта сүз бара.

Менюдагы ризыклар, ашлар һәм кулинария әйберләрен гадәттән тыш очракларда һәм мәҗбүри шартлар үтәлгәндә генә башкалырына алыштырырга рөхсәт ителә. Аларның азык кыйммәте бердәй булырга һәм азык-төлек продуктларын алыштыру таблицасына (санитар кагыйдәләрнең 6 кушымтасы) тәңгәл килергә тиеш. Моның тиешле хисаплар белән раслануы шарт. Әйтик, мәктәпкә тиешле чималны үз вакытында китермәү сәбәпле, сыер итеннән кәтлит әзерли алмасалар. Бу очракта 100 грамм сыер итен (аксым буенча бердәй күләмдә), 13 грамм ак май өстәп, 120 грамм балык (кылчыксыз тәрәч) белән алыштырырга мөмкин. Шулай ук эремчек һәм йомыркадан әзерләнгән ризыклар белән дә алмаштырып була.

**Итне алыштыру (аксым буенча)**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **Сыер ите (1 кат.)** | 100 | 18,6 | 14,0 | | |
| **Сыер ите (2 кат.)** | 90 | 18,0 | 7,5 | | Май +6 г |
| **Ярым майлы эремчек** | 110 | 18,3 | 9,9 | | Май +4 г |
| **Майлы эремчек** | 130 | 18,2 | 23,4 | 3,7 | Май -9 г |
| **Балык (кылчыксыз тәрәч)** | 120 | 19,2 | 0,7 | - | Май +13 г |
| **Йомырка** | 145 | 18,4 | 16,7 | 1,0 | |

Шуның белән бергә, менюда шул ук көнне яки алдагы 2-3 көнне бер үк ризыклар яисә кулинария әйберләре кабатланмаска тиеш (СанПиННың 6.13 пункты, 2.4.5.2409-08).

# «Батут үзәкләренә йөрмәсеннәр»

## Казандагы батут үзәкләренең берсендә башланган туган көн хастаханәдә тәмамланган.

Гөлнар **Гарифуллина**

**Казанда батут үзәгендә үткәрелгән бәйрәмнән соң унбер баланың өчесенә «умырткалыкта компрессион сыну» диагнозы куелган.**

Табиблар Казанда яшәүче Тәнзилә Гыйлемхановага батут үзәкләрен ябу турында петиция язарга киңәш биргән, чөнки әлеге үзәкләрдә имгәнеп хастаханәгә элэгүчеләр күп.

– Улым күптәннән батутта уйнарга барыйк дип сорап йөргәч, туган көнен батут үзәгендә билгеләп үтәргә булдык, – дип сөйләде **Тәнзилә Гыйлемханова**. – Иптәшләрен батут үзәгенә чакырдык, барлыгы 11 бала җыелды. Шунда табын әзерләдек. Балалар рәхәтләнеп батутта сикерде, уйнады, шикләнерлек берни дә юк иде кебек, инструкторлар да карап тора. Башта балалар буыннарын язылдырды. Аны җиңелчә генә ясадылар кебек тоелды, бик тиз генә батутка кертеп тә җибәрделәр. Соңрак кызыксынып белешә башладым: батутка әзерлексез керергә ярамый икән. Икенче көнне иртән улымның сыйныфташы чирләп киткән. Әнисе кич белән: «Кан басымы югары, пульсы да 140ка җитте, коса, баш мие селкенмәгәндер, егылмагандыр бит?» – дип шалтыратып сорады. «Юк, егылучылар, имгәнүчеләр булмады», – дидем. Шуннан алар Республика балалар клиник хастаханәсенә барган, рентгенга төшергәч, «сигезенче умырткада компрессион сыну» дигән диагноз куйганнар. Хастаханә сукмагын таптаучылар бер алар гына түгел. Абыйның – кызына, апаның улына да шундый диагноз куелган.

– Таудан шуа торган тюбингларның куркыныч икәнен белә идем. Менә бу хәл дә башкаларга гыйбрәт булсын иде, күбрәк кешегә ишеттерәсем килә: йөрмәсеннәр иде шул батут үзәкләренә. Аларны судка да бирә алмыйбыз бит, чөнки алдан килешү төзеп, җаваплылыкны өсләреннән төшерәләр, – дип искәртте Тәнзилә ханым.

## Бу хакта сөйләргә кирәк

Сикергән вакытта умырткага басым артып, алар кысыла. Хәтта озак сикереп, мәтәлеп китү нәтиҗәсендә дә компрессион сыну булырга мөмкин.

– Компрессион сыну – ул сөяк сыну кебек түгел, – дип аңлатты Республика балалар клиник хастаханәсе травматолог-ортопеды **Фәнис Гыйбадуллин**. – Умырткалык губка сыман матдәдән тора, көч килсә, алар бер-берсен «сыта». Соңыннан кифоз, ягъни бөкре чыгарга, остеохондроз, артроз авырулары баш калкытырга мөмкин.

Бала уйнаганда, батутта яки күнегүләр вакытында сикерсә яисә егылса, умыртка баганасының 5, 6, 7 сөягә «утыра» һәм нерв күзәнәкләре кысыла. Бу соң гына ачыкланырга мөмкин. Бала коса, башы авыртуга зарлана икән, димәк, умырткалыкның муен өлеше имгәнгән. Батут үзәкләрендә еш кына муеннарын имгәтәләр, чөнки бала сальто ясаганда ялгыш егыла, – дип сөйләде табиб.

Имгәнгән кешегә сәламәтләнү өчен иң мөһиме – режим саклау. Алты ай буе утырырга ярамый. Умыртка баганасының күкрәк өлеше бөгелмәсен өчен, корсет кияргә кирәк. Дәвалаулы физкультура күнекмәләре ясау, физиотерапия алу мөһим. «Бүген компрессион сыну очракларының якынча өчтән бере батут үзәкләрендә имгәнү белән бәйле», – ди Фәнис Гыйбадуллин.

«Тюбингларның зыяны турында күп сөйләделәр. Батут үзәкләренең зыяны турында да күбрәк сөйләсәк, бәлки уңай нәтиҗәсе булыр», – диде травматолог.

Батут үзәгенә күпме генә шалтыратсак та, балаларның батутта үз-үзен тоту кагыйдәләре турында аңлатып бирүче табылмады. Казан прокуратурасы исә әлеге очрак буенча тикшерү башлады.



Фото - pixabay.com